Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района



Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.12.2020 Менделеевск ш. №740

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 27 августындагы
476 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының "Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 26.02.2011 № 34-ОД боерыгы нигезендә, халыкның сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеше нормативларына ирешү һәм территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү зарурилыгы максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Менделеевск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2020 елның 27 августындагы 476 номерлы карары белән расланган Менделеевск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын 25 пункт белән Кушымта нигезендә тулыландырырга.
2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendelevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы С. В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Абдуллин

Кушымта
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 18 декабрендәге карарына

Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәре территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру
схемасына өстәмәләр

| п/п | Стационар булмаган сәүдә объекты төре | Урнашу урыны | Белгечлек | Урнашу вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 25 | Чыршы базары | Бурмистров урамы буенча 15 нче йорт «Юность» РМЙ арасында | Чыршы сату | Сезон сәүдәсе |